ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» августыннан № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларының, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы күренешенә карата таләпләрне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 15 статьясы («Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның үз көченә керүен исәпкә алып), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы күренешенә һәм архитектура чишелешенә бердәй таләпләр билгеләү һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясенең бердәй йөзен булдыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларының, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы күренешенә карата таләпләне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дамир Рөстәм улы Камалетдиновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «___» августындагы
____ номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларының, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы күренешенә карата таләпләр

1.1. Стационар булмаган сәүдә объектларының, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларының (алга таба – стационар булмаган сәүдә объекты, вакытлы объект) тышкы күренешенә карата таләпләр, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәге стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы күренешенә карата бердәй таләпләр кую юлы белән уңайлы мохит булдыру максатларында эшләнгән.

Стационар булмаган сәүдә объектының урнаштыруы территориядән файдалануның шәһәр төзелеше шартларына, техник регламентлар таләпләренә, санитар-эпидемиологик, экологик таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы таләпләренә туры килергә тиеш.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнаштырыла торган стационар булмаган сәүдә объекты стационар булмаган сәүдә объектларының, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларының тыш күренешенә карата таләпләргә туры килергә тиеш; аларның төп юнәлеше заманча, функциональ, визуаль яктан җәлеп итүчән стационар булмаган сәүдә объектларын, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын төзүдән гыйбарәт.

Стационар булмаган сәүдә объекты  техник яктан төзек хәлдә тотылырга тиеш. Ремонт эшләре кирәк булган очракта, мондый эшләр стационар булмаган объектның, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының тышкы кыяфәтен һәм төсләрен саклап калуны исәпкә алып башкарылырга тиеш.

1.2. Әлеге таләпләр максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

– стационар булмаган сәүдә объекты – инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтырылган яисә тоташтырылмаган булуына (технологик тоташтыру) карамастан, җир кишәрлегенә нык бәйле булмаган вакытлыча урнаштырылган корылма яисә конструкциядән гыйбарәт булган сәүдә объекты, шул исәптән күчмә корылма;

- павильон - сәүдә залы һәм товар запасын саклау өчен бүлмәләре булган, бер яисә берничә эш урынына исәпләнгән җиһазландырылган корылма;

- киоск - сәүдә җиһазлары белән җиһазландырылган, сәүдә залы һәм товарларны саклау бүлмәләре булмаган, сатучының бер эш урынына исәпләнгән, мәйданында товар запасы саклана торган корылма;

- вваклап сәүдә итү - стационар булмаган сәүдә объектларыннан, мобиль сәүдә объектларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла торган сәүдә эшчәнлеге, шулай ук тагып барыла торган һәм таратыла торган сәүдә, ярминкәләрдә, бәйрәм һәм башка бер тапкыр үткәрелә торган массакүләм чараларда сәүдә итү;

- вакытлы объектның эскиз проекты - вакытлы объектның тышкы күренешенә таләпләр билгели торган текст һәм график формадагы материаллар җыелмасыннан гыйбарәт документ.

1.3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнаштырыла торган стационар булмаган сәүдә объектлары түбәндәге төп таләпләргә туры килергә тиеш:

- объектлар тигез яисә махсус тигезләнгән мәйданчыкка тирәнәйтелгән фундаментлар урнаштырмыйча куелырга тиеш;

- объектларның тышкы күренеше, шул исәптән вакытлы объектларның параметрлары, төсле бизәлеше һәм вакытлы объектларның фасадларын бизәү материаллары Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге белән килештерелгән эскиз проектына туры килергә тиеш;

- стационар булмаган сәүдә объектының төсле бизәлешен формалаштыру RAL каталогы буенча, әйләнә-тирәдәге төзелеш архитектурасының төп заманча варианты нигезендә булырга тиеш;

- стационар булмаган сәүдә объектларының төп төсләр чишелеше: ак (RAL 9003, RAL 9010), соры (RAL 9006, RAL 9023, RAL 7024), кара (RAL 9004, RAL 9005, RAL 9011), агач текстурасы.

1.4. Стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы өслегендә күренеп торган пычранулар, зарарланулар, җимерелүләр булырга тиеш түгел, шул исәптән эскиз проектында каралган төс тонын үзгәртү булмаска тиеш.

1.5. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру белән кызыксынган зат эскиз проектын әлеге Таләпләр нигезендә мөстәкыйль эшләргә тиеш.

## 2. Стационар булмаган сәүдә объектларының архитектура-дизайнерлык чишелешенә таләпләр

2.1. Вакытлы объектларның тышкы күренеше заманча архитектура-сәнгать таләпләренә, чын таләпләргә җавап бирергә һәм, озак вакытлы эксплуатацияне исәпкә алып, үз сыйфатларын югалтмаска тиеш.

2.2. Стационар булмаган сәүдә объектлары өчен проект документациясе аларны заводта җитештерелгән җиңел җыелма терәк металл конструкцияләрдән генә монтажлау мөмкинлеген күздә тотарга тиеш. Сэндвич - панельләр, текстур һәм фактур өслеге төрле булган композит панельләр куллану рөхсәт ителә.

2.3. Стационар булмаган сәүдә объектлары өчен проект документациясе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге белән килештерелергә тиеш;

2.4. Стационар булмаган сәүдә объектларын әзерләү (модернизацияләү) һәм аларны бизәү өчен сыйфатлы һәм нык буяулы, бизәүле һәм эксплуатацияләү чоры дәвамында үзенең эстетик һәм эксплуатация сыйфатларын үзгәртми торган заманча сертификацияләнгән (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы өлешендә) материаллар кулланыла. Шул ук вакытта проектларда кирпеч, блоклар, бетон, сайдинг, рулон һәм шифер түбә куллану рөхсәт ителми.

2.5. Объектның керү төркеменең (төркемнәренең) архитектур һәм конструктив чишелеше, шулай ук объектның керү урыны (керү урыннары) территорияләре буенча хәрәкәт итүнең төп юллары таләпләргә («СП 59.13330.2016. Кагыйдәләр җыелмасы. Халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен биналар һәм корылмалардан файдалану мөмкинлеге. СНиП 35-01-2001 актуальләштерелгән редакциясе») (Россия Төзелеш Министрлыгының 2016 елның 14 ноябрендәге 798/пр номрлы боерыгы белән расланган) туры килергә тиеш.

2.6. Киоскларда, павильоннарда объектның профилен билгеләүче вывеска, теркәлгән исеме, милек рәвеше һәм объектның эш режимы күрсәтелгән мәгълүмати табличка булырга тиеш. Реклама-мәгълүмати бизәлешнең дизайнер карары павильонның архитектур-дизайнер карарына туры килергә тиеш.

## 3. Стационар булмаган сәүдә объектлары конструкциясенә һәм тышкы бизәлешенә таләпләр

3.1. Стационар булмаган сәүдә объекты корпусы.

Стационар булмаган сәүдә объектының ккаркасы тотып торучы эретеп ябыштырылган металл конструкцияләрдән ясалырга тиеш. Модульнең конструкциясе аны күчерү һәм транспортировкалау мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Атмосфера явым-төшемнәрдән саклану өчен стационар булмаган сәүдә объектының конструкциясендә козырек булырга тиеш.

Стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы фасадларына томат металл ишек полотналарын урнаштыру тыела.

3.2. Стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы бизәлеше.

Модульнең барлык тышкы өслеге, корпус, фриз, декоратив колонналар, реклама һәм мәгълүмат өслеге, аскы киртәләү элементларын кертеп, төрле текстур һәм фактур өслеге булган композит панельләр белән тышланган булырга тиеш.

Декоратив өслекләрнең төсләр гаммасы әйләнә-тирәдәге төзелеш архитектурасының төп заманча вариантына туры килергә тиеш.

3.3. Реклама-мәгълүмати бизәлеш.

Стационар булмаган сәүдә объектларын формалаштырганда түбәндәге төрдәге вывескалар кулланыла:

1) төп вывеска – стационар булмаган сәүдә объекты фасадында урнашкан, объектның исемен, шулай ук декоратив-сәнгать элементларын (логотип, товар билгесе һ.б.) үз эченә алып, сатыла торган продукциянең төрен билгеләргә мөмкинлек бирүче вывеска.

Төп вывеска күләмле яки яссы вариантта эшләнергә һәм турыдан-туры фасадка яки каты нигездә беркетелгән аерым хәрефләрдән һәм билгеләрдән торырга мөмкин.

Төп вывескада эчке яктырткыч булырга мөмкин.

Сәүдә павильоннары һәм киосклары өчен төп вывеска пыялаланган урын өстендә яки керү урыны өстендә урнаштырыла.

2) мәгълүмати табличка - стационар булмаган сәүдә объекты турында оешманың яки шәхси эшмәкәрнең исеме, урнашу урыны (адресы), эш режимы турында мәгълүматны үз эченә алган яссы вывеска.

Мәгълүмати табличканы барлык стационар булмаган сәүдә объектларында урнаштыру мәҗбүри.

Мәгълүмати табличка стационар булмаган сәүдә объекты фасадында күренә торган урында урнаштырыла, сәүдә павильоннарында - керү урыны янында яки керү ишегендә. Мәгълүмати табличка тексттан гына гыйбарәт булырга тиеш һәм чикләнгән үлчәмнәрдән - 0,5 м га 0,7 м узырга тиеш түгел. Фасадта урнаштыру мөмкин булмаган очракта (сәүдә павильоннарыннан кала) мәгълүмати табличка күренерлек урында урнаштырыла. Сәүдә арбаларда, сәүдә палатказларында, лотокларда, сезонлы характердагы башка стационар булмаган сәүдә объектларында төп вывеска урнаштыру тәкъдим ителә. Транспорт чаралары нигезендәге стационар булмаган сәүдә объектларында, сәүдә автоматында, сезонлы характердагы стационар булмаган объектларда төп вывеска өч үлчәмле яки яссы вариантта урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, оешма яки шәхси эшмәкәр турында мәгълүматны үз эченә алган ачык язу яки трафарет булырга тиеш.

3.4. Янындагы территорияне төзекләндерү.

Янындагы территория төзекләндерелгән булырга тиеш. Стационар булмаган объектлар урнаштыру өчен бүлеп бирелгән җир участоклары территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү. Яшелләндерү элементларының урнашуы һәм тышкы күренеше фасадның эстетик җәлеп итүчәнлегенә ярдәм итәргә, аны бизәүнең комплекслы чишелешен тәэмин итәргә тиеш.

## 4. Килештерүне таләп итми торган модуль типлары конструкциясендә үзгәрешләр

4.1. Стационар булмаган сәүдә объектлары конструкциясенә килештерүсез үзгәрешләр кертергә рөхсәт ителә, шул исәптән:

- фасадлардагы пыялалауның габарит үлчәмнәрен үзгәртмичә, товар тапшыру тәрәзәсенең урнашуы һәм үлчәме;
- ишек блокының урнашуы, үлчәме.

## 5. Стационар булмаган объектның (блокланган модульнең) билгеләнгән таләпләргә туры килүен билгеләү өчен параметрлар исемлеге

5.1. Сәүдә зонасында урнашкан стационар булмаган сәүдә объектының бу Таләпләргә туры килүен яки килмәвен билгеләгәндә, түбәндәге критерийлар кулланыла:

- бу Таләпләр белән билгеләнгән стационар булмаган сәүдә объектларының чикләнгән габарит үлчәмнәренә туры килү;
- тышкы бизәкләү материалларының һәм аларның төсләр гаммасының тәкъдим ителгән шушы Таләпләргә туры килүе;
- бер сәүдә зонасы объектлары өчен яисә бердәм модульгә (сәүдә галереясе) беркетелгән тышкы бизәкләү материалларының, тоташтыручы

декоратив элементларның һәм гомуми конструкцияләрнең (өске фриз һәм козырек) үлчәмнәренең тәңгәллеге.

5.2. Стационар булмаган сәүдә объектының чикләнгән габарит үлчәмнәре:

киосклар өчен - 30 кв.м дан күбрәк түгел;

павильоннар өчен - 50 кв.м дан күбрәк түгел.